ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 20 апреле** **Чистай шәһәре** **№ 228**

Социаль наем шартнамәсе буенча
торак урын мәйданының хисап
нормасы һәм торак урын мәйданын
бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын билгеләргә, аннан чыгып, гражданнарның торак урынының гомуми мәйданын биләүгә мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында аларның торак урынының гомуми мәйданының 18 квадрат метрыннан артмаган күләмендә тәэмин ителеш дәрәҗәсе билгеләнә.
2. Социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында бер гражданга торак урыны гомуми мәйданының 18 кв.метр күләмендә билгеләргә.
3. Торак урынның гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торакны исәпкә куйганда торак мәйданы нормалары турында» 2006 елның 22 июнендәге 640 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазифаларын башкаручы П.Б. Емельянов